РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«17» июнь 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 170

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы турында

2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 44 статьясына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставының яңа редакциясенә таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставын 1 нче Кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Әлеге карарны канунчылык белән кабул ителгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юлларга.
3. Әлеге карар көченә кергән көннән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 136 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы турында» карарын гамәлдән чыккан дип санарга.
4. «Кайбыч таңнары» район гәзитендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»ның информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин